МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.03.2018 г.Казань № 49/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында» 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында төзелгән «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына субсидияләр бирү турында» 2018 елның 9 февралендәге 082-09-2018-375 номерлы Килешүе нигезендә **боерам**:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында» 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына (22.05.2017 № 117/2-пр һәм 25.10.2017 № 240/2-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык белән расланган «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство программасында:

күрсәтелгән программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Боерык белән расланган крестьян (фермер) хуҗалыкларын булдыруга һәм үстерүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле уналтынчы һәм унҗиденче абзацлар өстәргә:

«куянчылык – кимендә 6 мең куян, шул исәптән кимендә 1000 ана куян (елга кимендә 10 тонна ит һәм кимендә 4 мең тонна тире);

гөмбәчелек – кимендә 1000 квадрат метр.»;

2.5 пунктның «с» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«с) Крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) башлыгының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре кайтару, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кайтару буенча түләнми калган бурычы һәм шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка түләнми калган бурычы юк;»;

2.5 пунктның «т» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«т) КФХ – юридик зат үзгәртеп кору, бетү, бөлгенлеккә төшү процессында түгел, ә КФХ – шәхси эшкуар шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктатмаган;»;

2.5 пунктның «у» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«у) КФХ әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы түгел;»;

2.6 пунктның сигезенче абзацын түбәндәгечә яңа редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен яңа авыл хуҗалыгы техникасы һәм инвентаре, йөк автомобиль транспорты, җайланмалар сатып алу;»;

3.1.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.16. Үз инициативасы белән салым органыннан КФХның Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган белешмә (форма: КНД буенча Код 1120101), КФХның дәүләт теркәвенә куелуы турында таныклык күчермәсе; конкурска заявка бирү көненә кадәр өч айдан да алданрак булмаган вакытта Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә һәм (яисә) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә, КФХ урнашкан урын буенча салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсе. Бу документлар КФХның үз инициативасы белән бирелмәгән очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала;»;

3.1.19 пунктны төшереп калдырырга;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.1.24, 3.1.25 пунктчалар өстәргә:

«3.1.24. 13 нче кушымта нигезендә, мөрәҗәгать итүченең җитештерү бинаналары, техникасы, җайланмалары, авыл хуҗалыгы терлекләре булуы турында белешмә;

3.1.25. КФХ милкендә булуны раслый торган техник чара паспорты.»;

5.6 пунктның җиденче абзацында «балларны саный һәм бәяләү

ведомстена кертә» сүзләрен «күрсәтмә характерындагы бәяләмәне конкурс комиссиясе каравына кертә чыгара» сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе заявкалар кабул итү тәмамланган көннән 15 эш көне эчендә тапшырылган документларны карый, конкурста катнашучылар исемлеген төзи, тапшырылган бизнес-планнарны Нигезләмә нигезендә бәяли, КФХ башлыклары белән очрашып сөйләшә һәм конкурс буенча сайлап алынучыларны билгели, бу хакта конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсен (алга таба – беркетмә) тутыра.»;

5.9, 5.10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләрне эксперт советының бәяләмәсе һәм мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны анализлау нигезендә, түбәндәге критерийларга таянып, билгели:

| Т/с № | Критерий исеме | Күрсәткечләр | Баллар белән бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Ферманың юнәлеше | сөтчелек | 3 |
| | | эре мөгезле терлекләр симертү | |
| | | ат үрчетү | 2 |
| | | бәрәңге үстерү | |
| | | яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта) | |
| | | дуңгызчылык | 1 |
| | | сарык, кәҗә үрчетү | |
| | | бөртекле һәм кузаклы культуралар, азык культуралары җитештерү | |
| | | җиләк-җимеш культуралары үстерү | |
| | | куянчылык | |
| | | гөмбәчелек | |
| | | кошчылык | |
| 2 | Яңа эш башлаучы фермерның яшәү шартлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыгы урнашкан урын буенча аның көнкүрешен көйләү дәрәҗәсе | милектәге торак | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | милектә булмаган торак (бергә яшәү яисә бергәләп файдалану) | 1 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир кишәрлеге булу** | милектә, түләүсз файдалануда | 3 |
| | | кимендә 6,5 елга – озак срокка арендалауда | 2 |
| 4 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җитештерү һәм склад биналары булу (шәхси ярдәмче хуҗалыкка карамаган) | милектә | 3 |
| | | арендада | 2 |
| 5 | Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен заявка бирү вакытына КФХ башлыгы милкендә үзйөрешле авыл хуҗалыгы техникасы булу (берәмлек) | 1дән 2гә кадәр | 1 |
| | | 3 һәм аннан күбрәк ел | 2 |
| 6 | Белеме, эш стажы булу | югары яисә урта махсус авыл хуҗалыгы белеме турында документы булу | 3 |
| | | авыл хуҗалыгында авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча КФХ башлыгы вазыйфасында кимендә өч ел эш стажы булу | 3 |
| | | мөрәҗәгать итүченең үзенең генә яисә бергәләп кимендә өч ел шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруы | 2 |
| | | өстәмә авыл хуҗалыгы белеме курсларын тәмамлавы турында документы булу | 1 |
| 7 | Бизнес-планның үз-үзен аклау срогы | 1 – 3 ел | 3 |
| | | 3 – 5 ел | 2 |
| | | 5 ел һәм аннан күбрәк ел | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | КФХның авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларында әгъзалыгы | кооператив әгъзасы | 2 |
| | | кооператив әгъзасы булмау | 0 |
| КФХ башлыгының проектны уңышлы гамәлгә ашыруның төп факторларын белүен бәяләү (үзе белән әңгәмәдән соң куела) | | | Иң югары балл - 5 |

Искәрмә: ** Балл тиешле хокуктагы гектарларның күпчелек саны буенча бәяләнә. Гектарлар саны бертигез булган очракта, бертөсле балл куела.

5.10. Бәяләнә торган проектларның һәркайсы буенча йомгаклау баллы чыгарыла, ул 5.9 пунктта күрсәтелгән критерийлар буенча мөрәҗәгать итүченең баллар суммасын билгели. Баллар бары тик тегелеп тапшырылган документлар буенча гына санала. Конкурс комисиясе утырышна тапшырылган документлар балл суммасына кушылмый. Балларның иң югары саны – 26. Конкурс комиссиясенең уңай бәяләмәсен алу өчен 11 балл җыярга кирәк.»;

6.5 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) конкурста җиңүчеләрне раслау турында Министрлык боерыгы;».

6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Идарә грантларны Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе территориаль бүлекчәләрендә ачылган КФХның шәхси счетларына Идарәнең шәхси счетына грантлар кергән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча күчерә.»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 2 - 5 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. КФХ ________________ – юридик зат үзгәртеп кору, бетү, бөлгенлеккә чыгу процессында түгел, ә КФХ ____________ – шәхси эшкуар, шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктатмаган.

3. КФХ Конкурс уздыру турындагы нигезләмәдә күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы түгел.

4. КФХның Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре кайтару, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кайтару буенча түләнми калган бурычы һәм шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка түләнми калган бурычы юк.

5. КФХның Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк.»;

Нигезләмәгә яңа 13 нче кушымта өстәргә (өстәлеп бирелә);

2, 8, 9 кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (алар өстәлеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыклары крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» программасына 2018 елда кертелгән үзгәрешләр турында хәбәр итәргә тиеш.

3. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары -министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгы (13.03.2018 № 49/2-пр боерыгы редакциясендә) белән расланган Программага 1 нче кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ**
**АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ**

# СЕРТИФИКАТ

*Серия НФ-___ № ______*

*Әлеге сертификат белән*

______________________________________________
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

*Россия Федерациясе гражданы паспортын*

______________________________________________
*(сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)*

______________________________________________

*һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күрсәтүче,*

______________________________________________
*(сериясе, номеры һәм датасы, ОГРНИП)*

*Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгы белән расланган "2017-2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм" программасында катнашучы була, дип танылa һәм аңа _______________ муниципаль районында крестьян (фермер) хуҗалыгын үстерүгә _____________ ( ______________________________ ) сум*
*(сүзләр белән)*
*грант бирелә.*

*Әлеге сертификат Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 20___елның "__"__________ номерлы боерыгы нигезендә бирелде.*

*Бирү датасы "___" __________201_ елның*

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –**
**Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы**
**һәм азык-төлек министры** **М.Г. Әхмәтов**

*«Ведомство программасында катнашу турында сертификат»*

Татарстан Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының 2017 елның 30
мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгы
белән расланган Нигезләмәгә
13 нче кушымта

Крестьян (фермер) хуҗалыгында җитештерү биналарының,
техниканың, җайланмаларның булуы турында, авыл хуҗалыгы
терлекләренең баш саны турында
БЕЛЕШМӘ

________________________муниципаль районы
__________________________________________авыл җирлегенең
20 __ елның «____»________________ торышы

| Т/с № | Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Эре мөгезле терлекләр саны – барлыгы, | баш | |
| | шулардан ана терлекләр саны – барлыгы, | баш | |
| | шул исәптән сөтчелек юнәлешендәге сыерлар | баш | |
| 2 | Атлар саны – барлыгы, | баш | |
| | шул исәптән 3 яшьлек һәм аннан зуррак яшьтәге бияләр | баш | |
| 3 | Дуңгызлар саны – барлыгы, | баш | |
| | шул исәптән ана дуңгызлар | баш | |
| 4 | Сарыклар саны – барлыгы, | баш | |
| | шул исәптән ана сарыклар | баш | |
| 5 | Кәҗәләр саны – барлыгы, | баш | |
| | шул исәптән ана кәҗәләр | баш | |
| 6 | Кош-кортлар саны – барлыгы,<br>шул исәптән (төрләрен күрсәтергә) | баш | |
| 7 | Булган техника (төрләрен һәм маркаларын күрсәтергә) | берәмлек | |
| 8 | Булган җир күләме | гектар | |
| 9 | Җитештерү бинасы (исеме, мәйданы) | квадрат метр | |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Җитештерү биналарына тоташтырылмалар – электр, су, газ, канализация, юл, (санап китәргә) | Ферма - _______, ________,<br>______ - _______ ________<br>______ - _______ ________<br>______ - _______ ________ |

______________________________ 20 ____ елның «____» ___________

(Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)

Мөһер (булса)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының 2017 елның 30 мартындагы
66/2-пр номерлы боерыгы белән (13.03.2018
№49/2-пр боерыгы редакциясендә) расланган
Нигезләмәгә
2 нче кушымта

# Катнашучы анкетасы

| Т/с № | Күрсәткеч исеме | Мөрәҗәгать итүче белешмәләре |
|---|---|---|
| 1. | Крестьян (фермер) хуҗалыгының (алга таба – КФХ) тулы исеме | |
| 2. | Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) | |
| 3. | Шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турында язманың төп дәүләт теркәү номеры (ОГРИП) | |
| 4. | Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы буенча эшчәнлек төре (ОКВЭД) | |
| 5. | Туу датасы | |
| 6. | Фактагы адресы (яшәү урыны) | |
| 7. | Теркәлү адресы | |
| 8. | КФХ эшчәнлеге фактта гамәлгә ашырыла торган авыл җирлеге исеме | |
| 9. | КФХны дәүләт теркәвенә алу датасы һәм урыны | |
| 10. | Авыл хуҗалыгындагы эш стажы | |
| 11. | Белеме, белгечлеге | |
| 12. | Төп (игълан ителгән) эшчәнлек буенча күздә тотыла торган еллык продукция күләме, мең сумнарда | |
| 13. | Аның каравындагы балалар саны | |
| 14. | Соңгы эш урыны, эштән китү датасы | |
| 15. | КФХның авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларындагы әгъзалыгы | |

КФХ башлыгы ____________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(имза)

Мөһер (булса)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының 2017 елның
30 мартындагы 66/2-пр номерлы
боерыгы белән
( 13.03.2018 № 49/2-пр боерыгы
редакциясендә) расланган
Нигезләмәгә 8 нче кушымта

**«2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» программасы буенча КФХ төзүгә һәм аны үстерүгә грант бирү турында**
**ШАРТНАМӘ**

Казан шәһәре № __________ 20___елның __ ______

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, алга таба «Грант бирүче» дип аталачак, бер яктан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов йөзендә, һәм, икенче яктан, Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районында теркәлгән крестьян (фермер) хуҗалыгы - шәхси эшкуар (алга таба – КФХ), дәүләт теркәве турындагы таныклык, ОГРНИП нигезендә эш итүче КФХ башлыгы ____________________________йөзендә, алга таба «Грант алучы» дип атлачак, алга таба бергә «Яклар» дип аталачак, конкурс уздыру йомгаклары буенча (конкурс комиссиясе утырышының 20__елның ___ ______ ____ номерлы беркетмәсе, Грант бирүченең бюджет акчалары бирү турында 20__елның ___ ______ ____ номерлы боерыгы) түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Грант бирүче Грант алучыга __________________________ КФХ төзүгә һәм аны үстерүгә грант бирә. (эшчәнлек юнәлеше)

1.2. Грант алучы грантны конкурс комиссиясе тарафыннан расланган чыгымнар планы нигезендә кулланырга йөкләмә ала.

1.3. Грант суммасы Грант бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең (алга таба – Идарә) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерелә, ә Идарә аны Грант алучының Федераль казначылыкның

Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерә һәм ул __________ (______________________________) сум тәшкил итә. (сүзләр белән язылa)

1.4. Шартнамәгә Казначылык күзәтүе «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2017 елның 5 декабрендәге 362-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда Казначылык күзәтүе кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1722 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Грант бирүченең хокуклары һәм бурычлары

2.1. Грант бирүче:

Грант алучының әлеге Шартнамә белән үзенә йөкләнгән бурычларны үтәвен тикшереп тора;

Грант алучыдан проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы финанс һәм башка беренчел исәпкә алу документларын соратып ала;

грантның проектны гамәлгә ашыруга гына тотылышын раслау өчен Грант алучы тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә, шулай ук проектның фактта гамәлгә ашырылуын тикшерә;

Грант алучыга карата Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Шартнамәдә каралган, хокук бозуларны бетерүгә һәм «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» ведомство максатчан программасы таләпләренең үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән гамәлләрне башкара.

2.2. Грант алучыга, әлеге Шартнамә төзелгән мизгелдән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, финанслау лимитлары булса, акчалар күчерү юлы белән грант суммасын түләүне гамәлгә ашыра.

2.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт чаралары турында» 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карарында каралган грант бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу факты (фактлары) билгеләнгән яисә алар турында дәүләт финанс контроле органыннан мәгълүмат алынган очракта, шул исәптән әлеге Грант алучы тарафыннан Шартнамә нигезендә тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелгән очракта, шул хокук бозулар бетерелгәнче грант бирү Грант бирүче тарафыннан туктатып торыла, бу хакта туктатып тору турында карар кабул ителү датасыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча катгый рәвештә Грант алучыга хәбәр ителә.

## 3. Грант алучының хокуклары һәм бурычлары

3.1. Грант алучы:

3.1.1. Федераль казначылыкның территориаль органында бюджет процессында катнашмаучы операцияләрен исәпкә алу өчен счет ача;

3.1.2. Федераль казначылыкның территориаль органына финанс белән

тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган чыгымнарны санкцияләүне гамәлгә ашыру өчен Россия Финанс министрлыгының «Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган чыгымнарны «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль законда каралган очракларда казначылык күзәтүендә санкцияләүне Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 8 декабрендәге 220н номерлы боерыгы белән расланган Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган чыгымнарны санкцияләүне Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибендә каралган документларны тапшыра;

3.1.3. Шартнамәләрдә (контрактларда, килешүләрдә), түләү һәм исәп-хисап документларында, шулай ук нигези документларда «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль законда каралган очракларда Казначылык күзәтүендә Россия Федерациясе валютасында капитал салулар турында дәүләт контрактының, учреждение контрактының, килешүнең, шартнамәнең идентификаторын булдыру тәртибен раслау турында” Россия Казначылыгының 2018 елның 9 гыйнварындагы 5н номерлы Боерыгында билгеләнгән идентификаторны күрсәтә (____________________);

3.1.4. Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алынган әйберләрнең һәркайсының хакыннан кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түләнүен раслый торган документларның Министрлык тарафыннан расланган форма буенча җыелма реестрын, күрсәтелгән документларның күчермәләрен (түләү йөкләнешләренең (поручениеләрнең), шартнамәләрнең, накладнойларның, фактура счетларының, ветеринария документларының, сатып алынган әйберләрне дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның күчермәләрен, сатып алынган әйберләрнең, ферманың эчке һәм тышкы яклары фотографияләрен) өстәп;

максатчан чыгымнарны түләүгә түләү йөкләнешен, максатчан чыгымнарны түләү буенча КФХда түләү йөкләмәләрен китереп чыгарган шартнамәләрне, үтәүченең (подрядчикның, поставщикның) тулы аталышы, товарның (хезмәт күрсәтүләрнең) исеме, чыгымнар планы нигезендә грант чикләрендәге суммага аларның саны (күләме) күрсәтелә;

3.1.5. Грант исәбенә гамәлгә ашырыла торган операцияләрнең аерымланган аналитик исәбен алып бару йөкләмәсен үз өстенә ала;

3.1.6. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм (яисә) 1.1., 1.2., 3.1. пунктларда билгеләнгән башка күрсәткечләр зурлыгына ирешүне тәэмин итә;

3.1.7. Грантны үзләштерә башлаган көннән алып 5 ел буена КФХ башлыгы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) «Эшчәнлек турында белешмәләр» формасы буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында яртыеллык һәм еллык хисаплар тапшыра. Хисаплар Грант алучы тарафыннан Идарәләргә Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча хисап чоры узганнан соң 10 көн эчендә тапшырыла. Идарәләр хисаплар кергәннән

соң 10 көн эчендә аларны килештерәләр һәм Министрлыкка җибәрәләр;

3.1.8. Грант алган көннән соң 18 ай эчендә Министрлыкка гранттан максатчан файдалану турында, Идарә башлыгы белән килештереп, «Җыелма реестр» формасы буенча хисап тапшыра, аңа хисап документлары өстәлеп бирелә. Хисап документлары дип, законнар нигезендә шулай дип танылган документлар атала (түләүне, товарлар алуны һәм (яисә) хезмәтләр күрсәтүне раслый торган документлар, фотографияләр). Хисаплар Грант алучының имзасы һәм мөһере (булса) белән таныкланган һәм Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районындагы Идарә башлыгы белән килештерелгән булырга тиеш;

3.1.9. Авыл хуҗалыгы эшчәнлеген грант үзләштерелеп беткәннән соң кимендә биш ел гамәлгә ашыра;

3.1.10. Грант алган елда грант ярдәменең һәр 1 миллион сумына кимендә бер даими яңа эш урыны булдыра, әмма бер грантка яңа бер даими эш урыныннан да ким булмаска тиеш;

3.1.11. Грантны үзенең шәхси счетына акчалар кергән көннән 18 ай эчендә куллана;

3.1.12. Үз акчалары исәбеннән чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алынган әйберләрнең хакыннан кимендә 10 процентын түли;

3.1.13. Грант алганнан соң 18 ай эчендә авыл хуҗалыгы терлекләренең баш санын Чыгымнар планында күрсәтелгән ______башка җиткерә, еллык җитештерү күләмен кимендә _________ кадәр тәэмин итә һәм аны грант суммасы үзләштерелгән көннән 5 ел дәвамында саклап кала;

3.1.14. Авыл хуҗалыгы продукциясенең үсешен грант бирелгән ел алдыннан булган дәрәҗәдән 10 процентка артуын тәэмин итә;

3.1.15. Грант бирүче һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Грант алучының грант бирү һәм куллану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр уздыруга ризалык бирә.

3.2. Икеяклы килешү буенча яклар, проект хакының чыгымнар планында күрсәтелгән кимендә 10 процентын үз акчаларыннан һәм (яисә) кредит акчаларыннан Грант алучы Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган бюджет процессында катнашмаучы операцияләрен исәпкә алу өчен шәхси счетка күчерә, дип килешәләр.

3.3. Грант исәбенә алынган активлар Грант алучы исеменә теркәлергә һәм Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районы территориясендә кулланылырга тиеш.

3.4. Грант исәбенә Грант алучы тарафыннан сатып алынган мөлкәт грант үзләштерелгән көннән 5 ел дәвамында законнар нигезендә бүләк ителми, арендага, куллануга тапшырылмый, алмаштырылмый, пай, кертем рәвешендә кертелми яисә башка рәвештә читләштерелми.

3.5. Алынган акчалар исәбенә КФХ башлыгы тарафыннан түбәндәгеләрне башкару тыела:

3.5.1. Югары технологияле чит ил җайланмаларын, чимал һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (кайтарганда) Россия

Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук бу чараларны алу максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, чит ил валютасын алу;

3.5.2. Башка юридик затның (юридик затның иярчен җәмгыятенең) устав (җыелма) капиталына взнос буларак, башка юридик затның (юридик затның иярчен җәмгыятенең) мөлкәтенә аның устав (җыелма) капиталын арттырмаслык кертем буларак, әгәр максатчан акчалар бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны күрсәтелгән юридик затка (юридик затның иярчен җәмгыятенә) аның Россия Федерациясе үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында ачылган счетларына күчерү мөмкинлеге каралмаган булса;

3.5.3. Акчаларны депозитларга, шулай ук башка финанс инструментларына урнаштыру масатларында, әгәр федераль законнарда яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында башкасы билгеләнмәгән булса;

3.5.4. Грант алучыга банкта ачылган счетларга акчалар күчерү тыела, моңа түбәндәге очраклар керми:

3.5.4.1. Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә Грант алучы йөкләмәләрен түләү;

3.5.4.2. Хезмәт хакына исәпләнгән суммаларны һәм социаль түләүләрне исәпкә алып, Грант алучының хезмәт өчен түләү буенча йөкләмәләрен түләү, шулай ук Грант алучының штатында тормый торган, максатчан акчалар бирелгәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен җәлеп ителгән хезмәткәрләр файдасына башка түләүләр;

3.5.4.3. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган Грант алучы тарафыннан фактта башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр, әзерләнгән продукция өчен түләү, әгәр Грант алучы эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү һәм продукция эзерләү өчен башка юридик затларны җәлеп итмәсә, шулай ук нигези документларны һәм (яисә) килешүләрдә, дәүләт контрактларында, капитал салулар турындагы шартнамәләрдә, учреждениеләр контрактларында, субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрдә (контрактларда, килешүләрдә) яисә норматив хокукый актларда каралган башка документларны биргәндә;

3.5.4.4. 3.5.4.3. пунктында күрсәтелгән, юридик зат тоткан чыгымнарны раслый торган документларны, түләү йөкләнешләре, түләү йөкләнешләре реестрлары күчермәләрен, шулай ук капитал салулар турында килешүнең, дәүләт контрактының, шартнамәнең, субсидияләр бирү турында учреждение контрактының һәм шартнамәсенең (контрактның, килешүнең) яисә башка норматив хокукый актның күчермәләрен тапшырганда (әгәр капитал салулар турында дәүләт контрактында, шартнамәсендә, учреждение контрактында һәм шартнамәсендә (контрактында, килешүендә) юридик зат тоткан чыгымнарны (чыгымнар өлешен) каплау каралган булса), Грант алучы тарафыннан тотылган чыгымнарны (чыгымнар өлешен) кайтару.

3.5.5. Юридик зат – максатчан акчалар алучы белән төзелгән

шартнамәләр (контрактлар, килешүләр), элемтә хезмәтләренә, коммуналь хезмәтләргә, электр энергиясенә, авиация һәм тимер юл билетларына, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетларга, матбугат басмаларына язылуга, арендалауга, юридик затларга караган инженерлык челтәрләрен, коммуникацияләрне һәм корылмаларны Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә күчереп урнаштыруга (яңадан төзүгә, тоташтыруга) шартнамәләрдән тыш, шулай ук иминләштерү законнары нигезендә төзелгән иминият шартнамәләре нигезендә банкларда ачылган счетларга күчерү.

3.6. Грантны куллану йомгаклары буенча Грант алучы гранттан максатчан файдалану турында «Килештерү кәгазен» Министрлыкның тармак бүлекләре, аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлыкларыннан һәм яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм итүгә грантлар бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыклары проектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе рәисеннән имзалата.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар үз йөкләмәләре өчен законнар нигезендә җаваплы булалар. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары грант бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аннан максатчан файдалануны законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерәләр.

4.2. Бирелгән грантлар, әгәр аларны бирү тәртибе, Шартнамәнең 3.1. пунктында билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, грантлардан максатчан файдаланмау йә грант алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелү фактлары ачыкланса, Министрлыкның таләбе алынган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.3. Күрсәтелгән акчаларны бюджет керемена ихтыярый рәвештә кайтарудан баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә тартып алынырга тиеш.

4.4. Грант алучы тарафыннан Министрлыкка һәм Идарәгә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык Грант алучыга йөкләнә.

4.5. Шартнамәне гамәлгә ашыру барышында барлыкка килергә мөмкин булган каршылыклар Яклар сөйләшүләре аша хәл ителергә тиеш.

Каршылыкларны сөйләшүләр аша хәл итеп булмаган очракта, алар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителергә тиеш.

4.6. Яклар Шартнамә буенча йөкләмәләрне тулысынча яисә өлешчә үтәү өчен җаваплылыктан бары тик форс-мажор хәлләр (РФ ГК, ст. 401, п.3) барлыкка килгәндә генә азат ителәләр. Әмма мондый хәлләр барлыкка килү үзе Грант алучының үз йөкләмәсен үтәвен туктатмый, әгәр аны бу хәлләр беткәннән соң үтәп була торган булса.

4.7. Шартнамә вакытыннан алда өзү, Якларның үзара килешүе буенча бюджет законнары нигезендә тиешле бюджетка___________сум

(______________________сум) күләмендә грантны кертkәч, башкарыла.
(сүзләр белән языла)

4.8. Шарнамәне Грант бирүче тарафыннан суд тәртибендә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 450 статьясы нигезендә өзү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

4.8.1. Грант алучы тарафыннан грант үтәлеше турында хисаплар бирелмәсә яисә алар тулысынча бирелмәсә һәм Шартнамә йөкләмәләре үтәлмәсә;

4.8.2. Хисап документлары тикшерелгәндә Грант бирүче тарафыннан ачыкланган белешмәләрне Грант алучы белә торып бозса;

4.8.3. Грант акчаларының максатчан тотылмавы ачыкланса;

4.8.4. Грант алучы тарафыннан эшчәнлек грант алынган көннән биш ел эчендә туктатылса һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыру буенча үзенә алынган йөкләмәләр Грант алучы тарафыннан үтәлмәсә;

4.8.5. Әгәр проект Шартнамә төзелгән көннән 18 ай эчендә мөһим сәбәпләрсез (каршы тора алмаслык хәлләр, ягъни гадәттән тыш хәлләр (җир тетрәү, давыл, су басу, янгын һ.б.лар), Грант алучының 18 айдан артыграк авыруы яисә җәрәхәтләнүе аркасында озак вакыт хезмәткә сәләтсез булу, якын туганы авыру аркасында аны карарга кирәк булу сәбәпле) гамәлгә ашырылмаса.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Шартнамә аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм 20______елның ___ __________ кадәр гамәлдә була.

5.2. Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара килешүе буенча аңа Яклар тарафыннан имзалана торган өстәмә язма килешү төзү юлы белән кертелә.

5.3. Шартнамә тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде, Якларның һәркайсына берәр нөсхә бирелде.

## 6. Якларның реквизитлары һәм имзалары

| Грант бирүче: | Грант алучы: |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | ________________________________ |
| | теркәлү адресы: ________________________________ |
| | ________________________________ |
| 420014, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт | яшәү адресы: ______________________ |
| | ________________________________ |
| р/с 40201810900000000002 НБ БҮЛЕКЧӘСЕ ТАТАРСТАН | паспорт: серия ______, №______________ |

<table>
<tr>
<td>
РЕСПУБЛИКАСЫ<br>
БИК 049205001<br>
Татарстан Республикасы буенча УФК (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Аппаратының ш/сч. ЛБ 007090001<br>
ИНН 1654019555<br>
КПП 165501001<br>
ОГРН 1021602854580<br>
<br>
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры<br>
<br>
М.Г. Әхмәтов ________________<br>
(имза)<br>
<br>
Мөһер урыны ________ 20__ ел.
</td>
<td>
бирелү урыны:_______________________________<br>
бирелү дата: ___________________________<br>
р/с _____________________________________<br>
_____________________________________<br>
(банк исеме)<br>
к/с ____________________________________<br>
__________________________________<br>
(банк исеме)<br>
БИК ___________________________________<br>
банкның ИНН<br>
_______________________<br>
КПП ___________________________________<br>
ОГРНИП (ОГРН) ______________<br>
КФХ башлыгының ИНН ____________<br>
<br>
________________ ________________<br>
(Фамилиясе, исеме, ат.ис.) (имза)<br>
<br>
Мөһер урыны (булса) __________ 20__ ел
</td>
</tr>
</table>

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгы белән (13.03.2018 № 49/2-пр боерыгы редакциясендә) расланган Нигезләмәгә 9 нчы кушымта

"КИЛЕШТЕРЕЛДЕ":
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы

____________________ /___________/

**2017-2020 елларда грант алучы крестьян (фермер) хуҗалыклары эшчәнлеге турында белешмәләр**

ТР _____________муниципаль районының ___________________КФХ 20____ елның ____ ___________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме,район)

**«2017-2020 елларга Татарстан Республикасында яңа эш башлаучы фермерларга ярдәм» программасы буенча**

**1. Терлекчелек буенча җитештерү күрсәткечләре:**

| | Терлекләрнең баш саны | | Җитештерел-гән авыл хуҗалыгы продукциясе исеме | Хисап чорына авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме | | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме | | Табыш, мең сум | Барлык чыгымнар, мең сум | Табышлылык, процент | Сату бәясе, сум/кило-грамм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Авыл хуҗалыгы терлекләренең исеме | Баш саны | | тонна | сум | тонна | сум | | | | |
| 1 | | | Сөт | | | | | | | | |

| | Авыл хуҗалыгы терлеклә-ренең исеме | Баш саны | | тонна | сум | тонна | сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | Сөт | | | | | | | | |
| 2 | | | Ит | | | | | | | | |
| 3 | | | Һәм башкалар | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Барысы:

**1. Үсемлекчелек буенча җитештерү күрсәткечләре:**

| № | Җитештерел-гән авыл хуҗалыгы продукциясе исеме | Урып-җыю мәйда-ны, гектар | Уңыш, тонна/ гектар | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме | | Авыл хуҗалыгы продукциясен сату күләме | | Табыш, мең сум | Барлык чыгымнар, мең сум | Табышлы-лык, процент | Сату бәясе, сум/ кило-грамм |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тонна | сум | тонна | сум | | | | |
| 1 | бөртекле һәм кузаклы культуралар | | | | | | | | | | |
| 2 | азык культуралары (күпьеллык үләннәр - печән) | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | бәрәңге | | | | | | | | | | |
| 4 | яшелчәләр | | | | | | | | | | |
| 5 | һәм башкалар | | | | | | | | | | |
| 6 | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы: | | | | | | | | | | | |

**2. Салым, хезмәткәрләр саны һәм аларның хезмәт хакы:**

| № | Хуҗалык хезмәткәр-ләре белгечлеге-нең исеме | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Исәпләнгән хезмәт хакы, мең сум | Салымнар, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барысы, салымнар | Шул исәптән | | | | |
| | | | | | Хезмәт хакыннан тотып калына торган суммалар | Җир салымы | Мөлкәткә салым | Транспорт салымы | Бердәм авыл хуҗалыгы салымы |
| 1 | КФХ башлыгы | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

| Җир кишәрлеге мәйданы (га): | милектә: | арендада: |
|---|---|---|

КФХ башлыгы ______________________________ / ____________/

(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)

Мөһер (булса)

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:

______________________________

(Элемтә өчен КФХ башлыгының телефон номеры)